Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№28 (41)

18 октябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**14 ОКТЯБРЬ** көнне Россия Юристлар ассоциациясенең Татарстандагы төбәкара бүлегенә караган Яшь юристлар советы вәкилләре **РУСЛАН ГАЛИУЛЛИН** һәм **РӨСТӘМ ШАКИРҖАНОВ** «Балалар университететы» проекты кысасында **БАРЛЫК ТЕЛӘҮЧЕЛӘР ӨЧЕН БУШЛАЙ ЮРИДИК КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР ҮТКӘРДЕ**. Алга таба һәр якшәмбе көнне, лекцияләр белән беррәттән, яшь юристларыбыз балаларның әти-әниләрен кызыксындырган, алар өчен актуаль булган сорауларга җавап бирәчәк.

• • • •

**15 ОКТЯБРЬ** көнне **ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы Үсеш программасының барышы белән таныштырды. Финанс эшләре буенча проректор Рәйсә Муллакаева 2012 елның дүртенче дүртъеллыгына, 2013 елга товарлар һәм эшләнәсе эшләр өчен сатып алынырга тиешле исемлек, план төзергә кирәклеген искәртте. Алга таба Телләр институты директоры Татьяна Иванова бүлекнең үсеш программасы белән таныштырды. Кабул итү комиссиясенең баш сәркатибе Сергей Ионенко КФУда 2013-2014 уку елына кабул итүгә бәйле әзерлек эшләре турында сөйләде. Ул база мәктәпләре белән булган эшчәнлек, КФУның төбәкара фән олимпиадалары, студент-волонтерлар турында мәгълүмат бирде.

• • • •

**15 ОКТЯБРЬДӘ КФУНЫҢ ЯР ЧАЛЛЫ ФИЛИАЛЫНДА «АЛТЫН КӨЗ» ДИП АТАЛГАН** факультет төркемнәренең җыелма командалары арасында **ФУТБОЛ БУЕНЧА VI ЯРЫШ ТӘМАМЛАНДЫ**. Чара бер ай буе дәвам итте һәм анда барлыгы 14 команда (112 уенчы) катнашты.

• • • •

**16 ОКТЯБРЬ** көнне **ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ КФУ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ПОЛЬШАГА КИТТЕ**. Делегация составында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин белән Икътисад һәм финанс институты директоры Шамил Вәлитовлар бар. 17 октябрьдә И.Гафуровның Вроцлав икътисад университеты профессоры Анджей Господарович белән очрашулары узды. Алар бүген икеяклы килешүгә кул куйды.

• • • •

**БҮГЕН СӘГАТЬ 14.30ДА** КФУның төп бинасында урнашкан икенче физика аудиториясендә **«ФРАНЦИЯ ҺӘМ ФРАНЦУЗЛЫЛАР ТУРЫНДА: ФРАНЦИЯ-РОССИЯ СӘҮДӘ-СӘНӘГАТЬ ПАЛАТАСЫ КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАГАНДА» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН СЕМИНАР УЗАЧАК**. Чараны CCIFRның директоры Павел Шинский алып барачак. Семинарда һәр теләгән кеше катнаша һәм теләгән сорауларын бирә ала.

• • • •


18 **ОКТЯБРЬ КӨННЕ СӘГАТЬ 16.30ДА** «Постсоциализм тикшеренүләренең мәдәни үзәге» дип исемләнгән фән-мәгариф үзәгенең дисциплинарара семинары кысасында **«РОССИЯДӘГЕ БӘХЕТ: СОЦИАЛЬ ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕ АНАЛИЗЛАУ, 1981-2011» АЧЫК ЛЕКЦИЯСЕ БУЛАЧАК**. Аны Санкт-Петербургның чагыштырма социаль тикшеренүләр лабораториясе җитәкчесе, профессор Эдуард Понарин уздырачак.

• • • •

**18-20 ОКТЯБРЬ** көннәрендә Казан федераль университетында **«ХӘЗЕРГЕ РОССИЯНЕҢ МӘГЪЛҮМАТИ КЫРЫ: ГАМӘЛЛӘР ҺӘМ НӘТИҖӘЛӘР» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН IX ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ УЗАЧАК**. Чараның оештыручысы булып журналистика һәм социология факультеты тора. Конференция кысасында «Хәзерге журналистика: бизнес? Сәясәт? Хәбәрдар булу?», «Журналистика тарихы: үткәндә булган хаталарны бүгенге массакүләм мәгълүмат чараларында ничек кабатламаска?» һәм «Хәзерге журналистика: яшь тикшеренүчеләр» секцияләре эшләячәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*






# Һәрбер халык - хәзинә!

Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында үткәрелә торган бүгенге халыкара фәнни-гамәли форум галимнәрне, дәүләт, җәмәгать эшлеклеләрен берләштергән бик әһәмиятле чара. Ул туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау, үстерү мәсьәләсенә багышланган.

Мәгълүм ки, җир шарында яшәүче һәр халыкның теле – чиксез кыйммәтле хәзинә. Күпләрне бүгенге көндә дөньядагы халыкларның ана телләрен, үзләренә генә хас мәдәниятләрен глобализация шартларында саклап калу мәсьәләсе борчый. Телләрне саклау һәм үстерү – дәүләт дәрәҗәсендәге, бөтен дөнья күләмендәге мөһим сәяси эш.

Билгеле булганча, җир йөзендә 5000гә якын тел бар. Россия Федерациясендә хәзерге көндә 160тан артык милләт һәм этник төркем яши. Мондый шартларда туган телләрне саклау – дәүләт этномәдәни сәясәтенең әһәмиятле юнәлешен тәшкил итә, милләтара тынычлыкны тәэмин итү чарасы булып та тора.

Бүгенге көндә кешеләрнең үзләре өчен яңа мөмкинлекләр ачу, башка халыкларның мәдәниятләре аша гомумкешелек кыйммәтләренә якынаюы, шәхесара һәм мәдәниятара аралашуга өйрәнүе аеруча мөһим. Боларны хәл итү өчен, телләрне өйрәнүнең әһәмиятен үстерү һәм киләчәк буыннарда үз халкына, мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү зарур.

Фәнни форумның эш юнәлешләре күптөрле. Аның кысаларында халыкара һәм бөтенроссия күләмендәге фәнни-гамәли конференцияләр, төп мәсьәлә турында фикер алышуга багышланган түгәрәк өстәл, укучылар өчен татар теленнән халыкара олимпиаданың йомгаклау туры, республика күләмендә укучылар өчен үткәрелә торган «Татарларга тылмачлар кирәк» конкурсы уздырылу – әлеге мәсьәләгә төрле яктан якын килүне, барыбызны да борчыган проблемаларны уртага салып фикер алышуны тәэмин итәчәк.

Форум эшендә илебез галимнәреннән тыш, АКШ, Япония, Төркия, Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Украина югары уку йортларыннан күпсанлы галимнәр, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашуы игътибарга лаек. Бу безгә туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау мәсьәләсендә тәҗрибә уртаклашырга, үсеш юлларын билгеләргә ярдәм итәчәк.

Шушы халыкара фәнни форумда катнашучыларга уңышлар һәм күпкырлы гыйльми-тикшеренү өлкәсендә яңа ачышлар телим!

*КФУ ректоры Илшат Гафуров*

## • Бердәм җину

# Ректорыбыз - депутат!

Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры Илшат Гафуров 14 октябрь көнне 45нче Апас сайлау округында (Апас, Тәтеш, Кайбыч һәм Кама Тамагы районнары) 84,58% тавыш җыеп, Илшат Гафуров җиңүгә иреште.



Халык үз тавышын ТР Дәүләт Советының өстәмә сайлауларында Россиянең иң өлкән һәм дәрәҗәле уку йорты җитәкчесе, «Алабуга» махсус икътисади зонасының һәм Алабуга музейлар комплексының актив вәкиле, республика һәм илебез үсеше өчен зур көч куйган шәхескә бирде.

Ректорыбызга карата оештырылган зур күләмдәге «кара пиар», КФУ тирәсендә һәм сайлаулар узарга тиешле урыннарда таратылган листовкаларга студентлар бер дә битараф калмады. Яшьләрнең Казан университеты һәм аның ректоры Илшат Гафуровның исеме һәм абруе өчен борчылулары сөенечле хәл.

12 октябрь көнне КФУ мәйданчыкларында – Филология һәм сәнгать институты, Икътисад һәм финанс институты, «УНИКС» комплексы янында студентлар Казан университетының абруен яклау акцияләре уздырды. Анда Казан университетының 1500дән артык студенты катнашты. Моннан тыш, 11 октябрь көнне КФУның Алабуга филиалында 200гә якын студент үзенчәлекле флешмоб үткәрде: акциядә катнашучылар берьюлы кулчатырлар ачып җибәрде. Бу – югары уку йортын нахак мәгълүматтан яклау билгесе.

Җыеннарда кабул ителгән резолюциядә студентлар: «Без – университетта белем алу дәрәҗәсенең һәм студентлар тормышының яхшыруына үзебез шаһит», - дип белдерә.

Илшат Гафуровны барлык хезмәткәрләр һәм студентлар исеменнән ТР Дәүләт Советы депутаты булуы белән чын күңелдән котлыйбыз! Бу җаваплы эшендә дә зур уңышлар телибез!

● Туган тел сагында

## Рәдиф Җамалетдинов:
# «Татар теле һәм әдәбияты үсештә!»

**Әңгәмәдәш – Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

18-21 октябрь көннәрендә КФУның Филология һәм сәнгать институтында зур чара – «Туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау һәм үстерү» халыкара фәнни-гамәли форумы уза. 3 елга бер мәртәбә үткәрелә торган форум бик күп проблемалар күтәреп, аларны чишү юлларын күрсәтә. Бу уңайдан без Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов белән әңгәмә кордык.

**– Рәдиф Рифкатович, форумның максаты нидә?**

– Соңгы елларда Россия, республикабыз күләмендә ана телләрен өйрәнү мәсьәләсенә карата төрле фикерләр әйтелә. Безнең фикеребезчә, әлеге проблема көн үзәгендә булырга тиеш. Бигрәк тә милли республикада. Форумда шушы проблемалар буенча тәҗрибә уртаклашу, яңа эш алымнары һәм формалары турында фикер алышу күздә тотыла.

**– Халыкара булгач, мондый җыенның географиясе дә зурдыр?**

– Әлбәттә, Россия галимнәре белән бергә, форум эшендә чит илләрдән дә хезмәттәшләребез катнашачак. Алар арасында АКШ, Япония,Төркия,Азәрбайҗан,Казахстан, Үзбәкстан, Украина һ.б. илләрнең җәмәгать эшлеклеләре, галимнәре һәм аспирантлары бар.

**– Форум кысаларында нинди чаралар үтәчәк?**

– 18 октябрь көнне «Татарларга тылмачлар кирәк!» республика конкурсының йомгаклау туры оештырыла. 19 октябрь көнне, төп ачылу тантанасы, форумның пленар утырышы, түгәрәк өстәл форматында сөйләшү планлаштырыла. Бу чаралар Татарстан урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Филология һәм сәнгать институтының актлар залында узачак. Шушы ук көнне тарихыбызда беренче мәртәбә татар теле һәм әдәбиятыннан халыкара олимпиаданың да ачылышы. 20 октябрь көнне дүрт фәнни-гамәли конференциянең секция утырышлары булачак.

**– Олимпиада турында тулырак мәгълүмат җиткерсәгез иде?**

– Олимпиада ике турда уза. Аның беренчесе – онлайн режимда, ә икенчесе шушы көннәрдә Казанда үтә. Онлайн режимда үткәрелгән сайлап алу турларында 2600дән артык мәктәп укучылары һәм студентлар катнашты. Икенче турда чит илләрдән һәм Россиянең 15ләп төбәгеннән килгән 80ләп катнашучы татар теле һәм әдәбияты, тарихы һәм мәдәнияте буенча көч сынашачак.

**–Конференцияләрнеңүзенчәлеге нидә?**

– «Классик филология һәм татар әдәбияты фәне» дип исемләнгән халыкара фәннигамәли конференция безнең уку йорты кысаларында беренче мәртәбә үткәрелә. Шулай ук күренекле тел галиме, профессор Флера Сафиуллина истәлегенә багышланган конференцияне дә Россия күләмендә беренче кат уздырабыз. Ә галим, филология фәннәре докторы Вахит Хаков истәлегенә багышланган «Хаков укулары» инде дүртенче мәртәбә оештырыла. Ул шунысы белән үзенчәлекле: бу конференциядә мәктәп укучылары, студентлар һәм аспирантлар катнаша. Моннан тыш, РГНФ һәм Татарстан фәннәр академиясе ярдәме белән инде өченче мәртәбә безнең уку йорты базасында уздырылып килә торган тагын бер конференция үтәчәк. Бу «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» дип исемләнгән безнең традицион конференциябез.



*Дөнья һәм Россия күләмендә рус теле, әдәбияты укытучыларының үз Ассоциациясе бар. Татар теле укытучыларының да үз ассоциациясен булдыру мөһим. Бу турыдагы тәкъдимнәр дә игътибарга лаек дип саныйбыз.*

**– Катнашучылардан килгән тәкъдимнәр арасында игътибарга лаеклылары бармы?**

– Әлбәттә. Бүген Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты, Татарстан фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә, татар телен һәм әдәбиятын саклау буенча төп үзәк ролен уңышлы гына үтәп килә. Шуңа күрә безнең базада Россия Федерациясе һәм БДБ илләренең төркителле төбәкләрендә туган телләрне, әдәбиятларны саклау һәм үстерүгә бәйле координацион совет оештыру фикере аеруча күп яңгырый.

Дөнья һәм Россия күләмендәрустеле,әдәбиятыукытучыларының үз Ассоциациясе бар. Татар теле укытучыларының да үз ассоциациясен булдыру мөһим. Бу турыдагы тәкъдимнәр дә игътибарга лаек дип саныйбыз.

Тагын бер тәкъдимгә тукталып үтәсе килә. Бу җәмәгатьчелек тәртибендә эшли торган Тукай институтын булдыру белән бәйле. Ишеткәнегез бардыр, Гете, Конфуций, Сервантес исемендәге институтлар үз телләрен һәм мәдәниятләрен пропагандалый. Әйтик, Гете институты немец теле һәм мәдәнияте буенча эшли. Аның төрле илләрнең югары уку йортларында үзәкләре бар. Безнең КФУда да Гете үзәге бик актив эшчәнлек алып бара. Күп кенә белгечләр, киң җәмәгатьчелек шушы үрнәк буенча Тукай институтын булдыру турындагы фикерен белдерде. Татар теле һәм мәдәниятен чит төбәкләрдә пропагандалау, бу юнәлештәге уку-укыту проектлары әлеге институт карамагына тапшырылса, нәтиҗәләр күпкә уңышлырак булыр иде.

**– Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәне ныгытуның тагын нинди юллары бар?**

– Бу уңайдан форумда катнашучылар белән «Tatarika» исемле халыкара журнал булдыру турында сөйләшергә уйлыйбыз. Аны электрон версиядә дә, басма формада да әзерләргә мөмкин. Биредә гуманитар өлкәгә бәйле мәкаләләр белән берлектә, техник юнәлештәгеләрен дә бастытырга мөмкин булачак. Безнең физика, химия һ.б. өлкәләрдә эшли торган татар галимнәребез бик күп. Аларның ачыш белән уңышлары халкыбыз, гомумән, барлык фәнни дөнья өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр иде.

**– Алдагы елларда да шундый зур дәрәҗәдәге форум оештырылырмы?**

– Ул өч елга бер мәртәбә уздырылуын дәвам итәр дип уйлыйбыз. Чираттагысы 2015 елда көтелә. Шул ук елны туган телләрне, әдәбиятларны өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр арасында конкурс оештырып, грант булдырып һәм форум кысаларында нәтиҗәләрне әйтеп, тиешле сертификатларны тапшыру тантанасын уздырырга дигән тәкъдим белән чыгабыз. Максатыбыз: яшь галимнәрне барлау һәм аларга әлеге юнәлештәге эшчәнлекләрен уңышлы дәвам итәргә булышу.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Рәдиф Рифкатович. Изге эшегездә зурдан-зур уңышлар телибез!**

# Гыйлем дөньясында

Алда билгеләп үткәнчә, форум кысаларында берничә зур конференция үтәчәк. Бу татар филологиясенә яшь галимнәр, яңа идеяләр килүе турында сөйли.

«Классик филология һәм татар әдәбият белеме: актуаль мәсьәләләр һәм үсеш перспективалары» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләрен берничә юнәлештә карау планлаштырыла. Татар галимнәре хезмәтләрендә тел һәм әдәбият мәсьәләләре» секциясе кысаларында татар әдәбият белеме үсешенә аерым өлеш керткән галимнәрнең фәнни мирасының өйрәнелү дәрәҗәсен барлау, аларның әдәбият белеме үсешенә керткән өлешен бәяләү мәсьәләләре каралачак.




«Хәзерге заман әдәбиятларында фикри-рухи һәм сәнгати эзләнүләр» секциясе эше замана әдәбиятындагы эзләнүләр-яңалыкларны ачыклау, әдәби текстта автор карашларының чагылыш үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана.

«Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларын фәлсәфи-эстетик аспектта өйрәнү» секциясендә борынгы төрки әдәби мирас, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятын гареп һәм шәрык әдәби бәйләнешләре җирлегендә өйрәнү, әдәби мирасны барлауның фәлсәфи-эстетик методологиясе, әдәби чыганакларны өйрәнү һәм текстология мәсьәләләренә багышланган докладлар турында фикер алышу күздә тотыла.

«Төрки халыкларның телләре, әдәбияты һәм мәдәнияте» секциясендә әдәби һәм мәдәни традицияләр, төрки халыкларның теле, тарихы, мәдәнияте, халык иҗаты мәсьәләләренә багышланган социаль-гуманитар эзләнүләргә багышланган чыгышларны тыңлау карала.

Конференциядә Төркия, Казахстан, Узбәкстан, шулай ук Россиянең Мәскәү, Хакассия, Төмән өлкәсе, Башкортстанның Уфа, Стәрлетамак, Татарстанның Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама һ.б. вузларыннан галимнәр катнашуы көтелә.

***

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков (1926-2008) – мәшһүр тел белгече, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының атказанган профессоры һәм башка бик күп мактаулы исемнәргә лаек бөек шәхес иде.

Вахит Хаков 1926 елны Буа районы Күзби авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне дә тәмамламаган 17 яшьлек егет сугышка китә.

1949 елны тыныч хезмәткә кайткач, Вахит Хаков берничә ел Буа районы мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Тәтеш педагогия училищесын, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Аспирантурадан соң, Казан университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшли башлый.

Үзенең бөтен гомерен галим татар телен фәнни яктан өйрәнүгә багышлый. Дистәләгән монография, дәреслек, уку-укыту әсбаплары, фәнни-методик хезмәтләре дөнья күрә. Ул 40 елдан артык Татарстан радиосында «Тел күрке – сүз» тапшыруларының оештыручысы һәм алып баручысы булып эшли.

Быел 16 августта галимгә 86 яшь тулган булыр иде. Вахит ага арабызда булмаса да, аның исеме бик еш телгә алына, хезмәтләре тел белеме өлкәсендә яңа фәнни эзләнүләр өчен нигез булып тора.



■ *Вахит Хаков укуларыннан күренешләр*

***

Форум кысаларында филология фәннәре докторы, профессор Флёра Садри кызы Сафиуллина истәлегенә багышланган Бөтенроссия «Фәнгә багышланган гомер» фәнни-гамәли конференциясе үтә.

Ф.С. Сафиуллина 1938 елның 24 маенда элекке Сарман (хәзерге Тукай районы) Теләнче Тамак авылында туа. 1960 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген кызыл диплом белән тәмамлый. Татар теле кафедрасында лаборант, аннары ассистент вазифаларын башкара. 1962-1965 елларда күренекле галим М.З. Зәкиев җитәкчелегендә аспирантура үтеп, 1966 елда «Татар телендә сүз тәртибе» дигән темага кандидатлык, 2000 елда «Татар әдәби теле синтаксисының үсеше (XX гасыр)» дигән темага докторлык диссертацияләре яклый. Галимә 1992-2008 елларда Казан дәүләт университетының татар теленә өйрәтү кафедрасын җитәкли. Чит ил һәм Россия университетлары белән фәнни-эзләнү элемтәсе булдыра.

Флёра Сафиуллина татар теленең синтаксисы, лексикологиясе, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы, лексикография, татар телен чит тел буларак укыту методикасы, мәктәп һәм вузлар өчен дәреслекләр төзү юнәлешендә эшли. Аның кырыктан артык китабы, йөзләгән фәнни мәкаләләре, өч йөзләп публикацияләре бар.

Флёра Садриевна – үзенең көчле фәнни мәктәбен булдырган галимә. Аның җитәкчелегендә дистәдән артык кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланды.

Ф.С.Сафиуллинаның фәнни-методик эшчәнлеге югары бәяләнде, ул дәрәҗәле дипломнар белән бүләкләнде, Каюм Насыйри исемендәге премиягә һәм «2000 ел Хатын-кызы» дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды.

● Безнең юбиляр

# Азат абый - ил агасы!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче



«Татар иленең мәшһүр төбәкләре бик күп: берәүләре урман-сулары, икенчеләре гыйбрәтле тарихы, өченчеләре күренекле кешеләре белән мәгълүм. Аллаһы Тәгалә Саба ягына боларның һәммәсен дә бүләк иткән», – дип башланып китте әдәбият галиме Азат Әхмәдуллинның 80 яшьлек Юбилеена багышланган кичә.

Бер тамчы суда бөтен диңгез күренә, диләр. Күренекле галим, педагог, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, җәмәгать эшлеклесе Азат Әхмәдуллин – туган төбәгенең асыл сыйфатларын туплаган шәхес. Кичәдә якташларының тагын бер кат Азат абыйны зурлавын, хөрмәт итүен, аның белән горурлануын күрдек.

Татар филологиясе бүлеге җитәкчелеге, укытучылар һәм студентлар белән әзерләнгән юбилей тантанасында мөхтәрәм остазыбызның биографиясеннән кызыклы мизгелләр, эшчәнлеге турында күп сөйләнде.



■ Могтәбәр галимнәр арасында

1932 елның 13 октябрендә Байлар Сабасы авылында күп балалы хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә Азат абый. Әти-әнисе – Гыйльмулла абзый һәм Дилшатбану апа – ипле, зыялы, гадел кешеләр була. Мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлаган егетне шул ук районның Шекше мәктәбендә мөгаллим итеп калдыралар. Бер ел дәвамында балаларга белем-тәрбия биргән Азат Әхмәдуллин 1951 елда КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Уку йортын кызыл дипломга тәмамлап, Татарстан китап нәшриятына эшкә урнаша. Биредәге эшчәнлеге озакка сузылмый. Аны Тубыл педагогика институтына укытучы итеп җибәрәләр. Гомәр Саттаров, Фәрит Хатыйпов, Әхәт Нигъмәтуллин кебек галимнәр белән студентларга белем-тәрбия бирүдән тыш, алар төбәкнең әдәби-мәдәни тормышын да җанландыра. «Тубылда яшәгән чорда үземне режиссер буларак та сынадым. К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектаклен сәхнәгә куйдым, Булат ролен дә уйнадым. Үзебез оештырып җибәргән дүрт тавышлы ансамбль дә зур уңышларга ирешә», – дип искә ала Азат абый. Татар филологиясе бүлеге мөдире, профессор Флера Сәйфулина Тубылдан кайнар сәламнәр җиткереп: «Без сезнең белән бер чорда яшәвебезгә һәм эшләвебезгә чиксез горурланабыз», – диде.

Азат Әхмәдуллинның эшчәнлеге күпкырлы. Ул – ничә буын студентның яраткан һәм алыштыргысыз остазы, мәктәп укучылары аны әдәбият буенча дәреслек авторы буларак таный, хезмәттәшләре кешелекле, гадел, ярдәмчел булганы өчен ярата. Институт директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов: «Безгә Азат абый белән күп еллар бергә эшләргә насыйп булды. Ул барлык яктан да үрнәк шәхес. Университет кысаларында гына түгел, бөтен татар халкы яшәгән җирдә аны хөрмәт итәләр», – диде һәм ТР Президенты аппарат җитәкчесе Юрий Камалтыновның котлау телеграммасын җиткерде, КФУ ректоры Илшат Гафуровның рәхмәт хатын тапшырды.

Галим күңел җылысын биреп эшләгән өлкәләренең берсе – драматургия. Ул аеруча Фәтхи Бурнаш иҗатын җентекләп тикшерә, бай мирасын яңадан халыкка кайтаруда күп көч куя. Кичәдә Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» спектакленнән куелган өзек һәркемнең күңеленә хуш килде.

«Мондый зур хезмәтләр язар өчен, ныклы терәк, гаилә бәхете кирәк. Ә Фирая апа – Азат абыйның төп фикердәше», – диде үз чыгышында Филология һәм сәнгать институты директоры урынбасары Рамил Мирзаһитов. Азат абый гомерлек тормыш юлдашы итеп Фирая ханымны сайлый. Фирая Юнысовна – татар мәктәпләре өчен рус теленнән язылган берничә дәреслек, методик әсбаплар авторы. Озак еллар Казан дәүләт педагогика институтында кафедра мөдире, профессор вазифаларын башкарды, хәзер лаеклы ялда. Алар бер ул һәм бер кыз тәрбияләп үстергәннәр, бүген дәү әти, дәү әни бәхетен татып яшиләр.

Бер кешегә дә кырын сүз әйтми, олыны олы, кечене кече итә торган Азат абый кичә ахырында студентларның сорауларына бик оста һәм кызыклы итеп җавап бирде. Без аның оста тальянчы икәнен дә белдек, заман белән бергә атлаучы галимнең бүгенге яшь буыннан калышмавын да аңладык. «80 яшь ул бик зур икән. Бер яктан куанычлы: нидер эшләнгән, сине хөрмәтлиләр. Икенче яктан аянычлы: картлык дигән әйбер бар», – дип йомгаклады чыгышын юбиляр. Юкка борчылмагыз, Азат абый. Сезгә яраткан студентларыгыз, хөрмәтле хезмәттәшләрегез белән яшисе дә эшлисе әле!

● Илһам канатында

# Ак кәгазьгә шигырь тама...

**Эльвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

*«Уйламассың инде...йомшак диеп,*
*Шундый йомшак минем Зөлфиям...»*
*яисә*
*«Әти-әни якын булган кебек,*
*Апаларын якын күрсеннәр!»...*

«Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсенең утырышына килгәннәр бу сүзләрне укуга язманың ни турында булганлыгын шундук аңлар...



11 октябрь көнендә «Илһам»ыбыз бик кызыклы үтте. Зөлфия Бәдретдинова белән Эльвина Нәҗипованың иҗатын бәяләү максатыннан, утырышыбызга гадәттәгечә «Илһам»ның яшь һәм өлкән иҗатчылары, шулай ук шагыйрь Рифат Сәлах та килгән иде. Алда сез укып киткән шигырь юллары да ике кызыбызның иҗатыннан.

Һәр утырыш та үзенә күрә бер кызыклы мизгелләр белән истә кала торгандыр. Бу очрашуда исә, күңелдә калганы – безнең студентларыбызның иҗат белән тирәнтен кызыксынулары, үзләренең фикерләрен курыкмыйча әйтә белүләре иде. Алай да кыюлыкны бераз арттырырга кирәк әле.

Рифат Сәлах ике кызыбызның да иҗатын үзенчә бәяләде. Аның тарафыннан тәнкыйть тә, шул ук вакытта хуплау сүзләре дә яңгырады. «Илһам» җитәкчесе Динара Әхмәт исә, Эльвинаның иҗатын зәңгәр күк йөзендәге кабарып торган ак болытлар белән чагыштырды. Кайберәүләр, Эльвина иҗатын укыгач, нигәдер ачык ишекне күз алдына китергән. Зөлфиянең иҗаты бүгенге көн проблемаларын да яктырта дип фикер йөртүчеләр дә бар иде. Шулай да ул күбрәк романтик шагыйрәдер.

Утырыш түгәрәк чәй өстәле артында тагын да җанлы, җылы булып тоелды. Яраткан мөгаллимәбез Ләйлә Минһаҗева, бүлегебез мөдире Флера Сәйфуллина, тәрбия эшләре буенча декан урынбасары Дамир Хөснетдинов та мәҗлесебездә катнашты. Кызларның шигырьләрен тыңлап, үзләренең төпле фикерләрен, теләкләрен җиткерде алар.

Утырыштагы катнашкан иҗатташ дусларыбыз Зөлфия белән Эльвинага, иҗатларына карата булган уй-фикерләрен, теләкләрен, хис-кичерешләрен белдерде. «Тәнкыйть утына тотылган» кызларыбызга Рифат «Яшел ай» исемле шигырьләр җыентыгын бүләк итте.

Утырышта катнашкан һәркем дә бер фикердә: «Әгәр синең күңелеңдә хисләр, сүзләр, фикерләр шигырь юллары булып ак кәгазь битенә тамам-тамам дип тора икән, димәк син аларны, һичшиксез, ак кәгазьгә төшерергә тиешсең. Кимендә үзең өчен булса да! Беренче вакытта рифмасы, ритмы туры килеп җитмәсә дә, киләчәктә барысы да уңышлы булыр. Иң мөһиме, күңелеңдә теләк булсын, өмет учагың беркайчан да сүнмәсен!»

«Илһам»ыбыз киләчәктә тагын да җанланыр, үзенең иҗатташ дуслары белән зур үрләргә күтәрелер, куйган максатларына ирешер дигән өметтә калабыз! Алла боерса, кызыклы очрашулар, утырышлар моның белән генә чикләнмичә, алдагы көннәребездә дә баер, үсәр дип ышанабыз!

● Ана теле

# Киләчәк рекламасы - татарча!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Татар телендәге реклама бүген күп кешеләрне шаккатыра. Чыннан да, «авылга кайткач әби белән генә сөйләшә торган» телдә Россия күләмендәге зур гына оешмаларның рекламаларын күрү нигәдер гаҗәп тоела безгә. Югыйсә, Татарстанда ана телебезнең дәүләт теле дәрәҗәсендә булуы һәркемгә билгеле. Туган телебезгә бүген «кухня теле» атамасы ныклап ябышкан. Бу – бик аяныч хәл. Татар теленең дәрәҗәсен күтәрү, җәмгыятьтәге урынын үстерү өчен, заманча ысулларга мөрәҗәгать итү зарури дип саныйм. Глобальләшү чорында традицияләрне, тарихны сакларга тырышып кына әллә кая китеп булмый!

Бүгенге цивилизацияне аннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел: урамнарны зур-зур реклама такталары «басып» алган, телевидение, радио, интернеттагы сайтлар реклама белдерүләре белән тулган, ул һәркайда: җитди массакүләм чараларыннан башлап, автобус-трамвайлардагы кечкенә билетларга кадәр. Әлбәттә, бу өлкәдә зур акчалар әйләнә: теләсә-нинди брендны алга чыгару күп чыгымнар таләп итә.

Күп кенә оешмалар өчен татар телендәге реклама уңышлы алым түгел. Күрәсең, «кухня теле»ндәге мәгълүмат беркемгә кирәкми, татар теленә бәйле теләсә-нинди әйбер бүген күпләрдә түбән сыйфат белән ассоциацияләнә. Кызганыч, килешергә туры килә.

Бөтендөнья татарларының башкаласы Казанда татар телендәге реклама җитештерә торган бер генә реклама агентлыгы да юк, интернетта - татар реклама сайты, матбугатта – реклама газет-журналлары күренми. Бу өлкәдә сыйфатлы, зур нәтиҗәләргә ирешеп эшләүчеләр булса, татар теле оятлы «кухня теле» атамасыннан азат ителер иде. Нәтиҗәдә, дәүләт теле исемен горур йөртердәй тел барлыкка килер иде. Шул очракта, татар рекламасына ихтыяҗ артып, татар матбугаты белән кызыксынучылар саны да күбәер. Университетыбызның татар бүлекләрендә белем алучы студентларга да кызыклы, замана таләпләренә туры килгән, югары хезмәт хакы ала торган эш урыннары да комачау итмәс.

«Без булдырабыз!» шигаре белән яшәүче халык без. Заманча ысулларны милли өлкәдә куллана алуыбызны, бу эшне дә уңышлы башкара белүебезне күрсәтергә вакыт!

***P.S.*** *Реклама дигәннән, бер кибеткә кердем. Хатын-кызлар тәмәкесенә дә татарча язып куелганын күргәч, күңелне каршылыклы хисләр биләп алды. Бер яктан, ана телендә реклама булуы күңелгә хуш килсә, икенче яктан, хатын-кызлар арасында тәмәке тарту халкыбыз өчен бөтенләй ят нәрсә. Хәер, бусы инде башка мәсьәлә.*

**Әдәби Ат**

# Шигъри үсентеләр

**Алмаз МАНСУРОВ**,
татар филологиясе бүлеге студенты

Бүген бөтен җир йөзен яңгыратып бер аваз ишетелде. Ул үзе бик матур булса да, сәер һәм серле иде.

Талларга кунып сайрашкан сандугачлар аны ишетеп:

– Шулай итеп чишмә генә челтерәп ага ала, – диештеләр.

Болытлар арасында уйнаклап йөргән тургайлар исә:

– Бу - җил. Җил генә шундый матур итеп сызгыра, – диеп хәбәр җиткерделәр.

Бу сүзләрне ишетеп, чишмә челтер-челтер килеп көлде дә җавап кайтарды.

– Мин түгел ул, дускайларым. Әйе, минем тавышым бик матурдыр да, әмма сафлыгы ягыннан ул бер ничек тә бу авазга тиңләшә алмый.

Ә җил җир йөзе буйлап шаярып узды да, бөтенләй көтелмәгән сүзләр сөйләде:

– Юк, сандугачлар, тургайлар. Сез ялгышасыз, – диде ул, – Әле генә сезне аптыраштa калдырган сәер аваз – бала тавышы.

– Бала?!

– Әйе, бала тавышы... Елаган тавыш. Беләсезме, бүген тагын бер сабый якты дөньяга килде, тагын бер җан иясе яралды. Ә бер гүзәл хатын-кыз Ана булды.

Бик тә сөенечле хәбәр. Аны ишетеп, бар табигать талпынып куйды. Болытлар арасыннан кояш утлы йөзен күрсәтеп, елмаеп җибәрде, елга ярларында чайпалып, җитезрәк агарга тырышты.

Дөнья ямьләнеп киткәндәй булды. Җиргә гүзәллек иңә түгелме?

Әнә бит, Ана сабыен кулларына алып күкрәгенә кысты. Шул хатынның күңеленнән бөркелгән наз нарасыеның да йөзенә күчте. Баланың битләре алсуланып китте, ул тирә-юньне яңгыратып көлеп җибәрде.

Могҗиза бит бу, могҗиза! Шул мизгелдә, Ана йөрәгеннән тамган хисләр чуар гөлләргә әйләнде. Ә күзләреннән бөркелгән сабыена карата мәхәббәте – күбәләкләр булып һавага күтәрелде.

Шулай итеп, җир йөзе гүзәл бакчага әйләнде.

Әкият диярсез сез... Бәлки шулайдыр да. Тик күңелемнең шул гүзәл әкияткә ышанасы килә. Җир йөзендә әниләребездән башка, болай ук рәхәт, болай ук матур булмас иде кебек.

Шундый уйларга бирелеп, урам буйлап атлыйм. Юл кырыена тезелгән йортларның тәрәзәләрендәге гөлләрне күзәтәм. Ниндиләре генә юк. Беләсегез килсә, әниләребез үстергән бит аларны!

Шулай ялт-йолт тирә-ягыма карана-карана үз йортыбыз янына кайтып җитәм, тәрәзәләребезгә күз салам. Ни генә әйтмә, иң матур гөлләрне минем әнием үстерә. Әнә бит ап-ак челтәрләргә төренеп, елмаешып утыралар. Әле мине сәламлиләр, кайтуыма да сөенәләр алар.



Шулай менә, Аллаһы Тәгалә әнкәйләребез кулына бик күп төрле орлыклар тоттыра. Әниләребез алар ярдәмендә җир йөзендә генә түгел, ә безнең күңелләребездә дә төрледән-төрле гөлләр үстерә. Безнең җаннарыбызда мәрхәмәт, кыюлык, тырышлык, намус кебек сыйфатлар да алар ярдәмендә шыткан.

Ә минем әнием, әле боларга өстәп, күңелемә шигърият орлыкларын да чәчкән. Алар шытып чыктылар. Кечкенә генә яшь үсентеләр хәленә килделәр. Ләкин бөтен йөрәгем белән ышанам: киләчәктә матурдан-матур гөлләр булырлар әле алар. Әле алай гына да түгел, чәчәк атып, бик күп кешеләрне сөендерерләр.

**Хикмәт**

## Рәхәт

**Булат ИБРАҺИМ** сандыгыннан,
татар филологиясе бүлеге студенты

Җитмешенче елларда булган хәл. Бер татар авылында ирләр эштән соң җыелышып, гадәттәгечә кич утыралар икән. Кызу бәхәс бара: «Рәхәт ничек була, рәхәт тормыш нәрсә ул?» – һәркайсы берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә нидер сөйли. Шулвакыт ирләр янына күп кенә еллар урыслар арасында яшәп кайткан Якуп абый килеп баса. Бер шаянрагы:

– Якуп абый, урысча рәхәт ничек була ул,- дип сорап куя.

– Урысчасын түгел, татарча рәхәтен дә күргән юк әле,- дип җавап кайтара Якуп абый.

**Кети-мети**

*Рус әдәбияты дәресе бара. Укытучы сорый:*

*– Йә, балалар, Лев Толстойның «Война и мир» әсәрен укып килдегезме? Класс тып-тын. Бер бала сикереп тора да, атылып чыгардай күзләре белән укытучыга мөрәҗәгать итә:*

*– Аны укырга кирәк идемени???*

*Укытучы:*

*– Әйе...*

*– Ә мин күчереп яздым!!!*

***

*Әтисе:*

*– Улым,көндәлегеңне бир әле.*

*– Мин аны Айратка биреп тордым...*

*– Ник?*

*– Ул әти-әнисен куркытмакчы...*

***

*Резюме яздым да, горурланып куйдым. Мин шундый яхшы кеше икән.*

***

*Бу дөньяда минем иремнән дә романтик кеше юк! Машина капотын тырнап йөрәк рәсемен ясаганымны күргәч, елап җибәрде.*

реклама




**Күчтәнәч**

**Галия ТӨХФӘТУЛЛОВА** (татар филологиясе бүлеге студенты) төзеде.


**Кроссворд сораулары.**

*Өстән аска:*

1. Дөньяның бөтен студент-спортчыларын берләштереп, бергә җыя торган чара.

Сулдан уңга:

1. Универсиадада якынча ничә мең спортчы катнашачак?
2. Казан Универсиадасына эстафетаны кайсы шәһәр тапшырды?
3. Универсиада эмблемасының кызыл төсе кайсы континентны аңлата?
4. «Баскет-холл»да уйналачак спорт төре.
5. Урта гасырлардан килгән спорт төре.
6. Универсиада эмблемасында зәңгәр төс кайсы континентның символы?
7. Кайсы шәһәрдә Универсиаданы Казанда үткәрү хокукы бирелде?
8. Казанда үтәчәк Универсиаданың символы булган барсның исеме.
9. Казанда үтәчәк Универсиаданың эмблемасында нинди чәчәк?
10. Универсиадада җиңүче хөрмәтенә яңгыраячак гимнның исеме.
11. FISU оешмасының президенты.




**!** Алдагы санда чыккан сканвордның җиңүчесе дә Галия булды. Бүләкне редакциябездән килеп алырга мөмкин. Кроссвордның җавапларын электрон почтабызга җибәрегез! Иң беренче дә, иң дөрес тә җавап биргән укучыбызны бүләк көтә.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Д.Р.Зиннәтова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.